ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.07.2017 Казан ш. № 6-67/тп

Татарстан Республикасы территориясендә лифтлар һәм кайнар су белән тәэмин итү максатларында электрдан җылытучы һәм кайнарлатучы җайланмалар белән тәэмин ителмәгән, яктырту, норматив технологик югалтулар, кайнар һәм салкын су белән тәэмин итүнең насос җайланмасы һәм башка җайланмалар төркемендә күпфатирлы йортның гомуми милегенә караучы җиһазланышлар төркеменә ия булган күпфатирлы йортлар өчен; лифтлар белән тәэмин ителгән һәм кайнар су белән тәэмин итү максатларында электрдан җылытучы һәм кайнарлатучы җайланмалар белән тәэмин ителмәгән, яктырту, норматив технологик югалтулар, кайнар һәм салкын су белән тәэмин итүнең насос җайланмасы, лифтларның ток җайланмасы һәм башка җайланмалар төркемендә күпфатирлы йортның гомуми милегенә караучы җиһазланышлар төркеменә ия булган күпфатирлы йортлар өчен халык тарафыннан йортның гомуми ихтыяҗларына электр белән тәэмин итү коммуналь хезмәтеннән файдалану нормативларын раслау хакында

Татарстан Республикасы Югары судының 2017 елның 14 июнендәге 3а-390/2017 номерлы карарын үтәү максатында Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елның 1 ноябреннән 2017 елның 1 июненә кадәрге чорга түбәндәгеләрне билгеләргә:

Шушы карар кушымтасына туры китереп, Татарстан Республикасы территориясендә лифтлар һәм кайнар су белән тәэмин итү максатларында электрдан җылытучы һәм кайнарлатучы җайланмалар белән тәэмин ителмәгән, яктырту,

норматив технологик югалтулар, кайнар һәм салкын су белән тәэмин итүнең насос җайланмасы һәм башка җайланмалар төркемендә күпфатирлы йортның гомуми милегенә караучы җиһазланышлар төркеменә ия булган күпфатирлы йортлар өчен; лифтлар белән тәэмин ителгән һәм кайнар су белән тәэмин итү максатларында электрдан җылытучы һәм кайнарлатучы җайланмалар белән тәэмин ителмәгән, яктырту, норматив технологик югалтулар, кайнар һәм салкын су белән тәэмин итүнең насос җайланмасы, лифтларның ток җайланмасы һәм башка җайланмалар төркемендә күпфатирлы йортның гомуми милегенә караучы җиһазланышлар төркеменә ия булган күпфатирлы йортлар өчен халык тарафыннан йортның гомуми ихтыяҗларына электр белән тәэмин итү коммуналь хезмәтеннән файдалану нормативларын.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
21.07.2017 ел № 6-67/тп карарына
кушымта

Йортның гомуми ихтыяҗларына электр белән тәэмин итү буенча
коммуналь хезмәттән файдалану нормативлары

| № п/п | Күпфатирлы йортларның категориясе | Күпфатирлы йортта гомуми милек булган җиһазланышлар төркеме | Үлчәү берәмлеге | Куллану нормативлары |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Лифтлар белән һәм кайнар су белән тәэмин итү максатлары өчен электрдан җылытучы һәм кайнарлатучы җайланмалар белән җиһазландырылмаган күпфатирлы йортлар | Яктырту, норматив технологик сарыфлар, кайнар һәм салкын су белән тәэмин итүнең насос җайланмасы һәм бүтәнчә җиһазланыш <*> | бер кв. метрга аена кВт·сәг | 0,523 |
| 2 | Лифтлар белән җиһазландырылган һәм кайнар су белән тәэмин итү максатлары өчен электрдан җылытучы һәм кайнарлатучы җайланмалар белән җиһазланмаган күпфатирлы йортлар | Яктырту, норматив технологик сарыфлар, кайнар һәм салкын су белән тәэмин итүнең насос җайланмасы, лифтларны ток белән җиһазлау һәм бүтәнчә җиһазланыш <*> | бер кв. метрга аена кВт·сәг | 1,024 |

<*> янгынга каршы җиһазланыш һәм төтен бетерү системалары, ишек бикләү җайланмалары, күмәк файдаланыла торган телеантенна көчәйткечләр.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге